| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ФЕДОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ФЕДОРОВСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 декабря 2025ел. Федоровский ав. № 14

Федоровский авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 20 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 04 августындагы 480 номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Федоровский авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 20 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 4 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта) мәҗбүри рәвештә күрсәтә, шулай ук алар буенча җавап, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамә җибәрелергә тиеш электрон почта адресын күрсәтә йә Бердәм порталда шәхси кабинетның адресын (уникаль идентификатор) файдалана. Граждан мондый мөрәҗәгатькә электрон формадагы кирәкле документларны һәм материалларны кушып бирергә хокуклы.»;

- 5 статьяның 2 өлешендәге 5 пунктчасында «вазыйфаи затка электрон документ формасында,» сүзләреннән соң «яисә аннан файдаланса, гражданның Бердәм порталдагы шәхси кабинетының адресы (уникаль идентификаторы) буенча, » сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https:// fedor-kaybici.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Житәкче Ф.Ф.Зәйнуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ Федоровского сельского поселения ИНН 1621003038